# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

"Халык сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре турында" 2005 елның 12 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның беренче абзацында "Россия Федерациясе Хөкүмәте" сүзләрен "Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы" сүзләренә алмаштырырга;

2) 9 статьяның 2 өлешендә "Россия Федерациясе Хөкүмәте" сүзләрен "Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы" сүзләренә алмаштырырга;

3) 10 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 марты
№ 14-ТРЗ